**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

12 ноябрь, 2021 ел Мәләкәс авылы № 21

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2021 елның 23 ноябренә 17:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылында Көнчыгыш, Елга, Басу, Урман урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының беренче этабын Мәләкәс авылы, Үзәк ур., 27А й. (авыл клубы бинасы) янында билгеләргә.

2. 2021 елның 23 ноябренә 18:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылында Үзәк, Яшьләр, Яшьләр тыкрыгы, Үзәк, Мәктәп урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының икенче этабын Мәләкәс авылы, Үзәк ур., 27А й. (авыл клубы бинасы) янында билгеләргә.

3. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мен) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

-янгын сүндерү машинасы өчен гаражны төзекләндерү (төзелеш материаллары, жиһаз сатып алу, проект эшләре);
- юлларны ремонтлау;
- урам яктырткычлары өчен электр материалларын сатып алу һәм урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар жыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Мәләкәс авылы, Үзәк урам, 27А.

4. Халык жыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл жирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7.Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл жирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев